**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
23.09.2020

КАРАР
№ПР-181

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең генераль планы проектына үзгәреш кертү турында**

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25, статьялары «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 октябрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставының 6 статьясындагы 14 пункты нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең генераль планы проектына үзгәреш кертергә.
2. Проектны эшләү вакытын 31.12.2020 елга кадәр дип билгеләргә.
3. Уразай авыл җирлеге башкарма комитетына проектны үзгәртү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турында физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм карауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Р.И.Гариповка йөкләргә.

**Җитәкче** **И.И.Габдулхаев**

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 0180CD78000CAB95AA4750138BB28C9CD3
Владелец: Габдулхаев Ильшат Ильфатович
Действителен с 21.11.2019 до 21.02.2021